**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-12-91

**2022елның 25 августы** **16/2 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының** Столбище **авыл җирлегендә аерым җир кишәрлекләрендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линияле объектлар төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең, кадастр номеры 16:24:150302:3457 булган җир кишәрлегенең территориаль зонасында,җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү - «махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасынннан" - СЗ - «9 катлы һәм аннан да югары катлы күпфатирлы торак йортлар төзү зонасы»торак-территориаль зонасына үзгәртү буенча- гавами тыңлаулар билгеләргә

2. Ачык тыңлаулар үткәрү датасын 2022 елның 07 сентябренә 10.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча билгеләргә: ТР, Лаеш районы, Столбище авылы, Заозерная урамы, 28 – нче йорт (КФҮ бинасы).

3. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Лаеш районы, Столбище авылы, Совет урамы, 103 йорт, эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр. 2022 елның 6 сентябренә кадәр.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы

буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).., - Столбище авылы, Совет урамы, 103 адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручыны йөкләргә..

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Ю.Романова**